РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 27 феврале № 10

Түбән Кама шәһәр Советының муниципаль контроль өлкәсендәге кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 29 һәм 65 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 548-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 59 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.8 пунктындагы 5 пунктчасында «аларның вәкилләре,» сүзләреннән соң «контрольдә тотыла торган зат өчен үз-үзен җайга сала торган оешмада мәҗбүри әгъзалык каралган булса,» сүзләрен өстәргә.

2. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.8 пунктындагы 5 пунктчасында «аларның вәкилләре,» сүзләреннән соң «контрольдә тотыла торган зат өчен үз-үзен җайга сала торган оешмада мәҗбүри әгъзалык каралган булса,» сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.И. Беляев